**РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН**
**АТНИНСКИЙ РАЙОННЫЙ СОВЕТ**

422750, село Большая Атня, улица Советская, дом 38

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
**ӘТНӘ РАЙОН СОВЕТЫ**

422750, Олы Әтнә авылы, Совет урамы., 38нче йорт

Тел.: 8(84369)21004, факс: 8(84369)21020, E-mail: atnya@tatar.ru, сайт: atnya.tatarstan.ru

РЕШЕНИЕ КАРАР

16 апрель 2024ел № 222

**Әтнә район Советының 07.11.2023 № 203 карары белән расланган Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районында муниципаль хезмәт турында нигезләмәгә үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү хакында**

«Россия Федерациясендә муниципаль хезмәт турында» 2007 елның 2 мартындагы 25-ФЗ номерлы Федераль законга, «Россия Федерациясе дәүләт хезмәте системасы турында "Федераль законның 12 статьясына һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү хакында" 2023 елның 12 декабрендәге 594-ФЗ номерлы Федераль законга ярашлы рәвештә, Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы Уставына таянып, Әтнә район Советы КАРАР ЧЫГАРДЫ:

1. Әтнә район Советының 07.11.2023 №203 карары белән расланган Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районында муниципаль хезмәт турында Нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертергә:

1.1. 5.3 пунктны түбәндәге эчтәлектәге 12 нче пункт белән тулыландырырга:

«12) «Россия Федерациясендә муниципаль хезмәт турында» гы Федераль законның 15_2 статьясында каралган анкетадагы мәгълүматларның аңа билгеле булган үзгәрешләре турында яллаучы вәкиленә (эш бирүчегә) язма рәвештә хәбәр итәргә, яллаучы (эш бирүче) вәкиле карары буенча үзгәртелгән мәгълүматлардан тыш(алга таба-анкетада булган мәгълүматлар).»;

1.2. 5.5 пунктның 8 нче пунктчасын түбәндәге эчтәлектәге яңа редакциядә бәян итәргә:

“8) муниципаль хезмәткә кергәндә һәм (яки) аны үткән вакытта ялган документлар һәм (яки) ялган мәгълүматлар тапшырулар, чикләүләрне үтәүне раслаучы, тыюлар һәм таләпләр каралган, аларны бозу муниципаль хезмәт вазыйфасын биләүгә комачаулый, яки документларны һәм (яки) мәгълүматны тапшырмау, чикләүләрне, тыюларны һәм таләпләрне үтәмәүне күрсәтүче, аларны бозу муниципаль хезмәт вазыйфасын биләүгә комачаулый”;

1.3. 9.3. пунктының 2 нче пунктчасын яңа редакциядә түбәндәге эчтәлектә бәян итәргә:

“2) “Россия Федерациясендә муниципаль хезмәт турында” Федераль законның 15_2 статьясында каралган анкета”;

1.4. 9.4. пунктта “мәгълүмат” сүзеннән соң “ (анкетада булган мәгълүматлардан тыш)” сүзләр белән тулыландырырга;

1.5. 20.1. пунктының 11 нче пунктчасын яңа редакциядә түбәндәге эчтәлектә бәян итәргә:

“11) муниципаль хезмәткә кергәндә һәм аны үткән вакытта граждан тарафыннан бирелә торган мәгълүматларны тикшерүне оештыру һәм үткәрү;”;

1.6. 21.7 пунктының беренче җөмләсен түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

“Максатлы укыту турында килешү төзү конкурсында катнашу хокукына Россия Федерациясенең дәүләт телен белгән, тиешле дәрәҗәдәге һөнәри белем алучы һәм укуны тәмамлаганнан соң хезмәт мөнәсәбәтләре барлыкка килүгә китерә торган укучы яки башка килешү буенча йөкләмәләре булмаган гражданнар ия”

2. Әлеге карарны Әтнә муниципаль районының рәсми сайтында: http://atnya.tatarstan.ru, һәм Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында «Интернет» мәгълүмати-телекоммуникация челтәрендә түбәндәге адрес буенча бастырып чыгарырга: http://pravo.tatarstan.ru

3. Әлеге карарның үтәлешен тикшерүне Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы Советының Җирле үзидарә органнары белән үзара хезмәттәшлек, законлылык, хокук тәртибе һәм регламент буенча даими комиссиясенә йөкләргә.

Глава Атнинского
муниципального района -
Председатель районного Совета Г.Г. Хакимов